**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# Об образовании Экспортного совета Республики Татарстан

В целях создания благоприятных условий для осуществления экспортной деятельности в Республике Татарстан **постановляю**:

1. Образовать Экспортный совет Республики Татарстан.

2. Утвердить Положение об Экспортном совете Республики Татарстан (приложение № 1) и его состав (приложение № 2).

3. Настоящий Указ вступает в силу со дня его подписания.

АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ГОМУМИ БҮЛЕК
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ

**Президент**
**Республики Татарстан** **Р.Н. Минниханов**

Казань, Кремль
21 апреля 2018 года
№ УП-326

Приложение № 1
к Указу Президента
Республики Татарстан

от «21» апреля 2018 года

№ УП-326

**Положение**
**об Экспортном совете Республики Татарстан**

1. Общие положения

1.1. Экспортный совет Республики Татарстан (далее – Совет) является коллегиальным совещательным органом по вопросам создания благоприятных условий для осуществления экспорта товаров и услуг.

1.2. В своей деятельности Совет руководствуется Конституцией Российской Федерации, федеральными законами, иными нормативными правовыми актами Российской Федерации, Конституцией Республики Татарстан, законами Республики Татарстан и иными нормативными правовыми актами Республики Татарстан, а также настоящим Положением.

2. Основные задачи Совета

2.1. Основными задачами Совета являются:

рассмотрение проекта стратегии в области обеспечения благоприятных условий для ведения экспортной деятельности в Республике Татарстан, анализ ее реализации, подготовка и рассмотрение предложений по корректировке стратегии;

подготовка предложений для включения в план развития экспортного потенциала Республики Татарстан и содействия выходу региональных компаний на внешние рынки, рассмотрение фактических показателей результативности мероприятий, предусмотренных планом;

разработка рекомендаций по организации взаимодействия исполнительных органов государственной власти Республики Татарстан, организаций, осуществляющих и планирующих вести экспортную деятельность на территории Республики Татарстан, и организаций, участвующих в поддержке и развитии экспортной деятельности в Республике Татарстан;

разработка рекомендаций по выявлению и уменьшению административных и иных барьеров, препятствующих развитию экспортной деятельности, осуществляемой организациями на территории Республики Татарстан;

подготовка предложений по приоритетным направлениям

осуществления экспортной деятельности в Республике Татарстан;

разработка рекомендаций по мерам государственной поддержки экспортной деятельности в Республике Татарстан;

подготовка предложений об увеличении объемов несырьевого экспорта Республики Татарстан.

## 3. Права Совета

3.1. Совет для выполнения возложенных на него задач имеет право:

рассматривать на своих заседаниях вопросы, относящиеся к его компетенции, и принимать по ним решения;

запрашивать и получать в установленном порядке от исполнительных органов государственной власти Республики Татарстан, территориальных органов федеральных органов исполнительной власти по Республике Татарстан, органов местного самоуправления муниципальных образований Республики Татарстан и организаций информацию в пределах своей компетенции;

вносить предложения по совершенствованию нормативного правового регулирования отношений в области экспортной деятельности;

приглашать на свои заседания руководителей и должностных лиц исполнительных органов государственной власти Республики Татарстан, территориальных органов федеральных органов исполнительной власти по Республике Татарстан, органов местного самоуправления муниципальных образований Республики Татарстан, иных органов и организаций.

## 4. Организация деятельности Совета

4.1. Положение о Совете и его состав утверждаются Президентом Республики Татарстан.

Совет формируется в составе председателя Совета, заместителя председателя Совета, секретаря Совета и членов Совета, которые участвуют в его работе на общественных началах.

В состав Совета могут входить представители исполнительных органов государственной власти Республики Татарстан, территориальных органов федеральных органов исполнительной власти по Республике Татарстан, организаций, осуществляющих экспортную деятельность на территории Республики Татарстан, общественных объединений предпринимателей.

4.2. Председателем Совета является Президент Республики Татарстан, заместителем председателя Совета – Премьер-министр Республики Татарстан.

Председатель Совета:

руководит деятельностью Совета;

определяет дату, время и место проведения заседаний Совета, повестку дня заседаний Совета и порядок их проведения;

ведет заседания Совета;

утверждает решения Совета.

В отсутствие председателя Совета его полномочия осуществляет заместитель председателя Совета.

4.3. Подготовку и организацию проведения заседаний Совета осуществляет секретарь Совета.

Секретарь Совета:

формирует и представляет председателю Совета предложения о дате, времени и месте проведения заседаний Совета, повестке дня заседаний Совета и порядке их проведения;

информирует членов Совета и приглашенных на его заседания лиц о дате, времени и месте проведения заседаний Совета, повестке дня заседаний Совета и порядке их проведения;

обеспечивает подготовку и направление членам Совета и приглашенным на его заседания лицам материалов к заседаниям Совета;

подготавливает и представляет проект протокола заседания Совета на утверждение председательствующему на заседании Совета;

обеспечивает контроль за исполнением решений Совета.

4.4. Заседания Совета проводятся по мере необходимости, но не реже одного раза в квартал.

4.5. Заседание Совета считается правомочным, если на нем присутствует более половины его членов.

Члены Совета обладают равными правами при обсуждении рассматриваемых на заседании Совета вопросов.

4.6. Решение Совета принимается простым большинством голосов присутствующих на заседании членов Совета. При равенстве голосов голос председательствующего на заседании Совета является решающим.

Решение Совета оформляется протоколом, который подписывается секретарем Совета и утверждается председательствующим на заседании Совета.

4.7. В работе Совета при необходимости могут принимать участие представители государственных органов, органов местного самоуправления, общественных и иных организаций, не входящие в его состав.

4.8. Организационно-техническое и информационно-аналитическое обеспечение деятельности Совета осуществляет Министерство промышленности и торговли Республики Татарстан.

---

Приложение № 2
к Указу Президента
Республики Татарстан

от «21» апреля 2018 года
№ УП-326

**Состав
Экспортного совета Республики Татарстан**

| | |
|---|---|
| Минниханов Рустам Нургалиевич | Президент Республики Татарстан, председатель Совета |
| Песошин Алексей Валерьевич | Премьер-министр Республики Татарстан, заместитель председателя Совета |
| Каримов Альберт Анварович | заместитель Премьер-министра Республики Татарстан – министр промышленности и торговли Республики Татарстан, секретарь Совета |
| Абдулганиев Фарид Султанович | министр экономики Республики Татарстан |
| Агеев Шамиль Рахимович | председатель правления Торгово-промышленной палаты Республики Татарстан (по согласованию) |
| Айдельдинов Айнур Тауфикович | директор некоммерческой организации «Инвестиционно-венчурный фонд Республики Татарстан» (по согласованию) |
| Ахметов Марат Готович | заместитель Премьер-министра Республики Татарстан – министр сельского хозяйства и продовольствия Республики Татарстан |
| Баширов Айрат Робертович | генеральный директор закрытого акционерного общества «Данафлекс» (по согласованию) |
| Бурганов Рафис Тимерханович | заместитель Премьер-министра Республики Татарстан – министр образования и науки Республики Татарстан |

| | |
|---|---|
| Гафеев<br>Рафаил Василович | генеральный директор акционерного общества «Внешнеторговая компания «КАМАЗ» (по согласованию) |
| Гиматдинов<br>Радик Рустамович | помощник Президента Республики Татарстан |
| Дьячков<br>Виктор Васильевич | генеральный директор акционерного общества «АйСиЭл-КПО ВС» (по согласованию) |
| Капустин<br>Евгений Николаевич | генеральный директор акционерного общества «Вакууммаш» (по согласованию) |
| Лаврентьев<br>Александр Петрович | президент Ассоциации предприятий и промышленников Республики Татарстан (региональное объединение работодателей) (по согласованию) |
| Мавликов<br>Альберт Вазилович | начальник Татарстанской таможни Приволжского таможенного управления Федеральной таможенной службы (по согласованию) |
| Минаева<br>Наталья Андреевна | руководитель проекта по развитию региональной системы поддержки экспорта акционерного общества «Российский экспортный центр» (по согласованию) |
| Минигулов<br>Фарид Гертович | генеральный директор Казанского публичного акционерного общества «Органический синтез» (по согласованию) |
| Минуллина<br>Талия Ильгизовна | руководитель Агентства инвестиционного развития Республики Татарстан |
| Мистахов<br>Ренат Искандерович | генеральный директор акционерного общества «Зеленодольский завод имени А.М. Горького» (по согласованию) |
| Мифтахов<br>Рафис Зуфарович | генеральный директор общества с ограниченной ответственностью «Казаньсельмаш» (по согласованию) |
| Нагуманов<br>Тимур Дмитриевич | Уполномоченный при Президенте Республики Татарстан по защите прав предпринимателей |

| | |
|---|---|
| Пустовгаров Юрий Леонидович | генеральный директор публичного акционерного общества «Казанский вертолетный завод» (по согласованию) |
| Рапопорт Ефим Фульевич | генеральный директор закрытого акционерного общества Научно-инженерного центра «Инкомсистем» (по согласованию) |
| Сагдиев Ильнур Ильдарович | управляющий директор открытого акционерного общества «Казанский завод компрессорного машиностроения» (по согласованию) |
| Садыков Марат Наилевич | министр здравоохранения Республики Татарстан |
| Саттаров Ильвир Разинович | директор общества с ограниченной ответственностью «П-Д Татнефть-Алабуга Стекловолокно» (по согласованию) |
| Соловьев Сергей Владимирович | директор общества с ограниченной ответственностью «ДжиДиСи Сервисез» (по согласованию) |
| Файзуллин Ирек Энварович | министр строительства, архитектуры и жилищно-коммунального хозяйства Республики Татарстан |
| Файзрахманов Марат Джаудатович | первый заместитель министра финансов Республики Татарстан – директор Департамента казначейства Министерства финансов Республики Татарстан |
| Хасанов Радик Шавкятович | генеральный директор акционерного общества «Производственное объединение «Завод имени Серго» (по согласованию) |
| Шайхутдинов Роман Александрович | заместитель Премьер-министра Республики Татарстан – министр информатизации и связи Республики Татарстан |
| Шакиров Нур Хамзинович | генеральный директор акционерного общества «Казанский медико-инструментальный завод» (по согласованию) |

| | |
|---|---|
| Шацких<br>Павел Александрович | генеральный директор открытого акционерного общества Казанского завода «Электроприбор» (по согласованию) |
| Ширинов<br>Адиль Шамиль Оглы | президент общества с ограниченной ответственностью «Форд Соллерс Холдинг» (по согласованию) |
| Шлёнский<br>Игорь Аркадьевич | управляющий директор по координации приоритетного проекта акционерного общества «Российский экспортный центр» (по согласованию) |
| Яруллин<br>Рафинат Саматович | генеральный директор открытого акционерного общества «Татнефтехиминвест-холдинг» (по согласованию) |

---

**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

## Татарстан Республикасы Экспорт советы оештыру турында

Татарстан Республикасында экспорт эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен уңай шартлар тудыру максатларында **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Экспорт советы оештырырга.

2. Татарстан Республикасы Экспорт советы турында нигезләмәне (1 нче кушымта) һәм аның составын (2 нче кушымта) расларга.

3. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2018 ел, 21 апрель
№ ПУ-326

Татарстан Республикасы
Президентының
2018 елның «21» апрелендәге
ПУ-326 номерлы Указына
1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы экспорт советы турында нигезләмә**

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы Экспорт советы (алга таба – Совет) товар һәм хезмәт күрсәтүләрне чит ил базарларына чыгару өчен уңай шартлар тудыру мәсьәләләре буенча коллегиаль киңәшмә орган булып тора.

1.2. Үз эшчәнлегендә Совет Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль законнарга, Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларына, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Татарстан Республикасы законнарына һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актларына, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.

2. Советның төп бурычлары

2.1. Советның төп бурычлары түбәндәгеләр:

Татарстан Республикасында экспорт эшчәнлеген алып бару өчен уңай шартлар тәэмин итү өлкәсендә стратегия проектын карап тикшерү, аны тормышка ашыруны анализлау, стратегиягә төзәтмәләр кертү буенча тәкъдимнәрне әзерләү һәм карап тикшерү;

Татарстан Республикасында экспорт мөмкинлекләрен үстерү планына тәкъдимнәр әзерләү һәм төбәк компанияләренең тышкы базарларга чыгуына ярдәм итү, план нигезендә каралган чараларның нәтиҗәлелегенең факттагы күрсәткечләрен карап тикшерү;

Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары, Татарстан Республикасында экспорт эшчәнлеген гамәлгә ашыручы һәм эшчәнлек алып барырга планлаштыручы оешмалар һәм Татарстан Республикасында экспорт эшчәнлегенә булышлык күрсәтүдә һәм аны үстерүдә катнашучы оешмалар арасында үзара бәйләнешләрне оештыру буенча тәкъдимнәр әзерләү;

Татарстан Республикасында оешмалар алып барган экспорт эшчәнлеген үстерүгә каршы торучы административ киртәләрне һәм бүтән каршылыкларны ачыклау һәм киметү буенча тәкъдимнәр эшләү;

Татарстан Республикасында экспорт эшчәнлеген гамәлгә ашыруның өстенлекле юнәлешләре буенча тәкъдимнәр эшләү;

Татарстан Республикасында экспорт эшчәнлегенә дәүләт ярдәме чаралары буенча тәкъдимнәр эшләү;

Татарстан Республикасында чимал булмаган экспорт күләмнәрен арттыру буенча тәкъдимнәр эшләү.

## 3. Советның хокуклары

3.1. Совет үзенә йөкләнгән бурычларны башкару өчен түбәндәгеләргә хокуклы:

үзенең утырышларында үз компетенциясенә караган мәсьәләләрне карап тикшерергә һәм алар буенча карарлар кабул итәргә;

Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарыннан, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнарыннан, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарыннан һәм оешмалардан үз компетенциясе кысаларында мәгълүмат соратырга һәм алырга;

экспорт эшчәнлеге өлкәсендә норматив хокукый җайга салуны камилләштерү буенча тәкъдимнәр кертергә;

үз утырышларына Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнары, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары, башка органнар һәм оешмалар җитәкчеләрен һәм вазыйфаи затларын чакырырга.

## 4. Совет эшчәнлеген оештыру

4.1. Совет турындагы нигезләмәне һәм аның составын Татарстан Республикасы Президенты раслый.

Совет составы Совет рәисе, Совет рәисе урынбасары, Совет секретаре һәм аның эшчәнлегендә җәмәгать башлангычларында катнашучы Совет әгъзаларыннан формалаштырыла.

Совет составына Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнары, Татарстан Республикасы территориясендә экспорт эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмалар, эшмәкәрләрнең иҗтимагый берләшмәләре вәкилләре керә.

4.2. Совет рәисе булып Татарстан Республикасы Президенты, Совет рәисе урынбасары булып Татарстан Республикасы Премьер-министры тора.

Совет рәисе:

Совет эшчәнлегенә җитәкчелек итә;

Совет утырышлары уздыруның датасын, вакытын һәм урынын, көн тәртибен һәм аларны уздыру тәртибен билгели;

Совет утырышларын алып бара;

Совет карарларын раслый.

Совет рәисе булмаганда, аның вәкаләтләрен Совет рәисе урынбасары гамәлгә ашыра.

4.3. Совет утырышларын уздыруны әзерләү һәм оештыру эшен Совет секретаре гамәлгә ашыра.

Совет секретаре:

Совет утырышлары уздыруның датасын, вакытын һәм урынын, көн тәртибен һәм аларны уздыру тәртибен формалаштыра һәм Совет рәисенә тапшыра;

Совет утырышлары уздыруның датасы, вакыты һәм урыны, көн тәртибе һәм аларны уздыру тәртибе турында Совет әгъзаларына һәм аның утырышларына чакырылган затларга мәгълүмат бирә;

Совет утырышларына материаллар әзерләүне һәм аларны Совет әгъзаларына һәм аның утырышларына чакырылган затларга юллауны тәэмин итә;

Совет утырышы беркетмәсе проектын әзерли һәм Совет утырышында рәислек итүчегә раслауга тапшыра;

Совет карарлары үтәлешен контрольдә тотуны тәэмин итә.

4.4. Экспорт советы утырышлары кирәк булган саен, әмма кварталга кимендә бер тапкыр үткәрелә.

4.5. Совет утырышында аның әгъзаларының яртысыннан артыгы катнашса, ул гамәлгә хокуклы санала.

Утырышларда карап тикшерелә торган мәсьәләләр турында фикер алышканда Совет әгъзалары тигез хокукларга ия.

4.6. Советы карарлары аның утырышта катнашкан әгъзаларының гади күпчелек тавышы белән кабул ителә. Тавышлар тигез булган очракта, утырышта рәислек итүченең тавышы хәлиткеч була.

Совет карары беркетмә белән рәсмиләштерелә, аңа секретарь имза куя һәм утырышта рәислек итүче тарафыннан раслана.

4.7. Совет эшендә, кирәк булганда, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, җәмәгать оешмалары һәм башка оемаларның аның составына керми торган вәкилләре катнаша ала.

4.8. Совет эшчәнлеген оештыру-техник һәм мәгълүмати-аналитик тәэмин итүне Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы гамәлгә ашыра.

Татарстан Республикасы
Президентының
2018 елның «21» апрелендәге
ПУ-326 номерлы Указына
2 нче кушымта

**Татарстан Республикасы экспорт советы составы**

| | |
|---|---|
| Миңнеханов<br>Рөстәм Нургали улы | Татарстан Республикасы Президенты, Совет рәисе |
| Песошин<br>Алексей Валерьевич | Татарстан Республикасы Премьер-министры, Советы рәисе урынбасары |
| Кәримов<br>Альберт Әнвәр улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министры, Совет секретаре |
| Габделганиев<br>Фәрит Солтан улы | Татарстан Республикасы икътисад министры |
| Агиев<br>Шамил Рәхим улы | Татарстан Республикасы Сәүдә-сәнәгать палатасы идарәсе рәисе (килешү буенча) |
| Әйделдинов<br>Айнур Тәүфыйк улы | «Татарстан Республикасы Инвестиция-венчур фонды» коммерциячел булмаган оешмасы директоры (килешү буенча) |
| Әхмәтов<br>Марат Готыф улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры |
| Бәширов<br>Айрат Роберт улы | «Данафлекс» ябык акционер җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча) |
| Борһанов<br>Рафис Тимерхан улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры |

| | |
|---|---|
| Гафиев<br>Рафаил Васыйл улы | «КАМАЗ» тышкы сәүдә компаниясе» акционер җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча) |
| Гыйматдинов<br>Радик Рөстәм улы | Татарстан Республикасы Президенты ярдәмчесе |
| Дьячков<br>Виктор Васильевич | «АйСиЭл-КПО ВС» акционер җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча) |
| Капустин<br>Евгений Николаевич | «Вакууммаш» акционер җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча) |
| Лаврентьев<br>Александр Петрович | Татарстан Республикасы предприятиеләре һәм сәнәгатьчеләре ассоциациясе (төбәк эш бирүчеләр берләшмәсе) президенты (килешү буенча) |
| Мәүликов<br>Альберт Вазыйл улы | Федераль таможня хезмәтенең Идел буе таможня идарәсе Татарстан таможнясы башлыгы (килешү буенча) |
| Минаева<br>Наталья Андреевна | «Россия экспорт үзәге» акционер җәмгыятенең экспортка булышлык күрсәтү төбәк системасын үстерү проекты җитәкчесе (килешү буенча) |
| Миңнегулов<br>Фәрит Герт улы | Казанның «Органик синтез» гавами акционер җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча) |
| Миңнуллина<br>Талия Илгиз кызы | Татарстан Республикасы инвестицион үсеш агентлыгы җитәкчесе |
| Мистахов<br>Ренат Искәндәр улы | «Зеленодольскиның А.М. Горький исемендәге заводы» акционер җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча) |
| Мифтахов<br>Рәис Зөфәр улы | «Казансельмаш» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Нагуманов Тимур Дмитриевич | Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил |
| Пустовгаров Юрий Леонидович | «Казан вертолет заводы» гавами акционер җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча) |
| Рапопорт Ефим Фульевич | «Инкомсистем» фәнни-инженерлык үзәге ябык акционер җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча) |
| Сәгъдиев Илнур Илдар улы | «Казан компрессор машиналары төзү заводы» ачык акционер җәмгыяте идарәче директоры (килешү буенча) |
| Садыйков Марат Наил улы | Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министры |
| Саттаров Ильвир Рәзин улы | «П-Д Татнефть-Алабуга Стекловолокно» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры (килешү буенча) |
| Соловьев Сергей Владимирович | «ДжиДиСи Сервисез» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры (килешү буенча) |
| Фәйзуллин Ирек Әнвәр улы | Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министры |
| Фәйзрахманов Марат Җәүдәт улы | Татарстан Республикасы финанс министрының беренче урынбасары – Казначылык департаменты директоры |
| Хәсәнов Радик Шәүкәт улы | «Серго исемендәге завод» җитештерү берләшмәсе» акционер җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча) |
| Шәйхетдинов Роман Александрович | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы мәгълүматлаштыру һәм элемтә министры |

| | |
|---|---|
| Шакиров<br>Нур Хәмзә улы | «Казан медицина инструментлары заводы» акционер җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча) |
| Шацких<br>Павел Александрович | Казанның «Электроприбор» заводы ачык акционер җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча) |
| Ширинов<br>Адил Шамил Оглы | «Форд Соллерс Холдинг» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте президенты (килешү буенча) |
| Шлёнский<br>Игорь Аркадьевич | «Россия экспорт үзәге» акционер җәмгыятенең өстенлекле проектны координацияләү буенча идарәче директоры (килешү буенча) |
| Яруллин Рафинат<br>Самат улы | «Татнефтехиминвест-холдинг» ачык акционер җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча). |